**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 ноябрь № 903

г. Казань

Татарстан Республикасы Президентының 2016 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасын тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте гамәлләренең комплекслы планы турында

Татарстан Республикасы Президентының 2016 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасында билгеләнгән төп нигезләмәләрне һәм бурычларны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы Президентының 2016 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасын тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте гамәлләренең комплекслы планын (алга таба – План) расларга.

2. Планны тормышка ашыруда катнашучы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 сына кадәр Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына аны үтәү барышы турында мәгълүмат кертергә.

3. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Планны тормышка ашыруда катнашучы федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, Татарстан Республикасы предприятиеләренә һәм оешмаларына хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 сына кадәр Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына аны үтәү барышы турында мәгълүмат кертүне;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы Президентының 2016 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасында билгеләнгән төп нигезләмәләрне һәм бурычларны тормышка ашыру чараларын күрүне һәм хисап кварталыннан соң килә торган айның

10 сына кадәр Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына аларны тормышка ашыру барышы турында мәгълүмат җибәрүне.

4. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына алынган мәгълүматны гомумиләштерергә һәм квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган икенче айның 5 сенә кадәр, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\903.docx